МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»
Полковая ул., 9, с. Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422701

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
Полковая урамы, 9, Биектау поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422701

Тел.: +7 (84365) 3-28-54, e-mail: pizobiektau@mail.ru

РАСПОРЯЖЕНИЕ **БОЕРЫК**

14.01.2021 г. **№ 6-б**

Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2020 елның 13 июлендәге 202-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары,

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасының 2020 елның 28 январендәге 17-р номерлы боерыгы белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертергә: 1 нче кушымтаның 39.6 статьясындагы 2 пунктның 3.1 пунктчасында «Россия Федерациясенең» сүзләреннән соң, «күрсәтелгән Федераль закон нигезендә, белешмәләре проблемалы объектларның бердәм реестрына кертелгән күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка күчемсез мөлкәт объектларын төзү тәмамлангач,» сүзләре белән тулыландырып, «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге боерыкны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис С.М.Минһаҗев